Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

19.06.2026 ел Менделеевск ш. № 53

Менделеевск муниципаль районы Советының 2013 елның 30 сентябрендәге 212 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Бюджетара мөнәсәбәтләрне камилләштерү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 августындагы 307-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.Менделеевск муниципаль районы муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме Менделеевск муниципаль районы Советы карары белән расланган җирле бюджет турында карар белән чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) муниципаль берәмлек бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләменнән ким булмаган күләмдә раслана:

1) автомобиль бензинына акцизлар, турыдан-туры куылган бензин, дизель ягулыгы, Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган дизель һәм (яисә) карбюратор (инжектор) двигательләр өчен мотор майлары;

2) транспорт салымыннан җирле бюджетлар кереме (әгәр Россия Федерациясе субъекты законы белән җирле бюджетларга транспорт салымыннан түләүләрнең бердәм нормативлары билгеләнгән булса);

3) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау исәбенә җирле бюджетларның кереме;

4) авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен җирле бюджетлар керемнәре;

5) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган җирле бюджетка муниципаль юл фонды төзүне күздә тоткан башка кертемнәр.
Муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме, фактта хисап финанс елында кергән һәм аны төзегәндә фаразланган җирле бюджет керемнәре күләме арасындагы аерманы исәпкә алып, чираттагы финанс елында үзгәрешләр кертергә тиеш.»

1. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирле үзидарә һәм финанс-бюджет мәсьәләләре буенча депутатлар комитетына йөкләргә.

Совет рәисе Р.Р. Искәндәров